**Территорияне планлаштыру проекты, «Яр Чаллы - Сарман автомобиль юлын реконструкцияләү, км 22+480-км 26+030» линия объекты территориясен ызанлау проекты буенча халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү**

**1.** Территорияне планлаштыру проекты, «Яр Чаллы - Сарман автомобиль юлын реконструкцияләү, км 22+480-км 26+030» линия объекты территориясен ызанлау проекты буенча халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итәбез.

**2. Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**
- Планлаштыру проектының төп өлеше;
- Территорияне планлаштыру проектын нигезләү буенча материаллар;
- Территорияне ызанлау проектының төп өлеше;
- Территорияне ызанлау проектын нигезләү буенча материаллар.

**3. Проект буенча халык тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм сроклары:**
Проект буенча халык тыңлауларs 2026 елның 8 маеннан 2026 елның 22 маена кадәр чорда үткәрелә.
Халык тыңлауларын үткәрү процедурасы түбәндәге этапларны үз эченә ала:
- халык тыңлаулары башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтта урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- халык тыңлаулары беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**4. Халык тыңлауларында катнашучылар даирәсе:**
Проект буенча халык тыңлауларында катнашучылар булып тора:
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк, Теләнче -Тамак, Иске Дөреш авыл җирлекләре территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Яңа Бүләк, Теләнче-Тамак, Иске Дөреш авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләренә һәм (яки) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларына хокук ияләре,
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган биналарның хокук ияләре.

**5. Чикләрендә халык тыңлаулары уздырыла торган территория:** Тукай муниципаль районы.

**6. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозицияләрен ачу урыны һәм датасы:** 15.05.2026
- Яңа Бүләк авылы, Тукай ур., 38 йорт, авыл мәдәният йорты бинасы;
- Бай Бүләк авылы, М.Җәлил ур., 20 йорт, ФАП бинасы;
- Күктәк-Мирсәет авылы, Һ.Такташ ур., 21, ФАП бинасы;
- Иске Теләнче авылы, Ленин ур., 24, ФАП бинасы;
- Иске Дөреш авылы, Тукай ур., 21, авыл мәдәният йорты бинасы;
- Салих-Тукай авылы, Комсомольская ур., 1 йорт;
- Октябрь Бүләге авылы, М.Җәлил ур., 28А, ФАП бинасы;
- Таулы Дөреш авылы, Ленин ур., 52 йорт, ФАП бинасы;
- Җикәнлекүл поселогы, М.Җәлил ур., 33 йорт;
- Теләнче-Тамак авылы, Татарстан ур., 19, авыл мәдәният йорты;
- Останково авылы, Үзәк ур., 8 йорт;
- Казаклар авылы, Н.Шәрипов ур., 40, авыл мәдәният йорты;
- Таулык авылы, Үзәк ур., 24, авыл мәдәният йорты;

- Хуҗи авылы, Үзәк ур., 34.

**7. Проект экспозициясен үткәрү сроклары:** 2026 елның 15 маеннан 2026 елның 22 маена кадәр чорда.

**8. Экспозицияне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:**дүшәмбе-җомга 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр.

**9. Халык тыңлауларында катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм формасы:**

2026 елның 15 маеннан 2026 елның 22 маена кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык тыңлауларында катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

- рәсми сайт аша;
- халык тыңлауларын оештыручы адресына язма рәвештә яки электрон документ формасында: Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 101 каб. (дүшәмбе - җомга, 09:00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр);
- халык тыңлауларында каралырга тиешле проект экспозициясенә килүчеләрне исәпкә алу китабына (журналына) язу юлы белән.

РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5 статьясы 12 өлеше нигезендә идентификация узган халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларында катнашучыларның җыелышларын үткәрү барышында язма яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.

**10. Халык тыңлауларында катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**

Проект буенча халык тыңлаулары **2026 елның 22 маенда 16:00 сәгатьтә Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында түбәндәге адрес буенча узачак: Яр Чаллы шәһәре, Муса Җәлил проспекты, 46 йорт, 2 кат, утырышлар залы.**

**11. Халык тыңлауларында каралырга тиешле проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**

Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) 2026 елның 15 маеннан «Документлар/иҗтимагый һәм халык тыңлаулары» өстәмә битендә урнаштырылачак.

**12. Әлеге хәбәрнамәне** «Светлый путь» газетасында бастырып чыгарырга.

Башкарма комитет Җитәкчесе

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 15AE296FD75F49CE6CBF538F55CA0DD1
Владелец: Маняпов Линар Нурисламович
Действителен с 11.11.2025 до 04.02.2027

Л.Н. Маняпов